| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОШУГУРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ШӨГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 3 сентябре № 26

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган 2021 һәм аннан соңгы елларга Иске Шөгер авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә (06.03.2024 № 9 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган 2021 һәм аннан соңгы елларга Иске Шөгер авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә (06.03.2024 № 9 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 пункттан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:

«Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама таләп ителмәгән дип таныла торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.»;

2) 15.1 пунктны төшереп калдырырга;

3) 16.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Иске Шөгер авылы, Иске Шөгер авылы, Совет ур., 1нче йорт - балалар бакчасы бинасы, Совет урамы, 3нче йорт, М. Җәлил ур., Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми

сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова

ИНН 1649012917
КПП 164901001